| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_28.01.2025____ Казан ш. № _под-93/25_____________

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, «2024 елга, 2025

һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүгә вәкаләтле булган республика башкарма хакимият органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибен расларга.

2. Милли мәгариф бүлегенә (Э.Х.Гыйзәтуллина) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытта дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.З.Закироваga йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ________________ № __________ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибе

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә (алга таба – Учреждение) Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү кагыйдәләрен (алга таба – Тәртип) билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

Дәүләт программасы – 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы;

Гамәлгә куючы – Учреждениегә карата оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

субсидия – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет

ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына Чараны гамәлгә ашыруны финанс яктан тәэмин итүгә билгеләнгән тәртиптә Гамәлгә куючыга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә акчаларны төп бүлүче һәм алучы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Гамәлгә куючы тарафыннан Учреждениегә бирелә торган субсидия.

әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

3. Субсидия Учреждениегә Дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

## II бүлек. Субсидияне бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидияне алу максатында Учреждение Гамәлгә куючы адресына субсидия алу өчен гариза (алга таба – гариза) бирә, ул түбәндәге документларны үз эченә ала:

әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатка субсидия бирү кирәклеген дәлилләүче аңлатма язуы, шул исәптән субсидия суммасын исәпләү-дәлилләү, шул исәптән Дәүләт программасы чараларын уздыруга чыгымнарның башлангыч сметасы;

субсидия алу өчен гариза тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салым органы белешмәсе, ул Учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар буенча үтәлмәгән бурычның булмавын расларга тиеш;

гариза бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага булган торышында Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычларның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрнең, бюджет инвестицияләренең булмавы турында җитәкче һәм баш хисапчы тарафыннан имзаланган, Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш.

Тапшырылган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение җитәкчесенең язма мөрәҗәгате Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелергә һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланырга яки Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән расланган булырга тиеш. Субсидия алу өчен документлар әзерләүнең барлык чыгымнарын Учреждение үз өстенә ала.

Учреждение үзе тарафыннан элегрәк тапшырылган Гаризаны кире алырга һәм аны кабат тапшырырга хокуклы.

Учреждение тарафыннан гаризалар, электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасын кулланып, электрон рәвештә җибәрелгән очракта, алар Учреждение җитәкчесенең яисә Учреждение җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручының электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

5. Гариза кергән көнендә теркәлә.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә бирелгән гаризаны алганнан соң 10 эш көне эчендә аны карый, анда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм Учреждениегә субсидия бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

6. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә Гамәлгә куючы һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәк нигезендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи, анда, шул исәптән, түбәндәге нигезләмәләр дә була:

субсидияне бирү максаты, Чараның атамасын күрсәтеп;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

субсидиянең күләме;

субсидияне күчерү вакыты (графигы);

финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында, килешүне үтәү турында хисаплылык тапшыру чорлары һәм тәртибе;

Учреждение килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисаплылык тапшыру тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Гамәлгә куючыга Субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;

Гамәлгә куючы карары буенча килешүне берьяклы тәртиптә вакытыннан алда туктату нигезләре, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:

Учреждениене үзгәртеп кору (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерүгә бәйле рәвештә;

әлеге Тәртиптә һәм (яки) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатын һәм шартларын бозу;

Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә.

Кирәк булуга карап, Гамәлгә куючы һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәкләр нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

7. Бирелә торган субсидиянең күләме $(C)$ әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә тапшырылган Гаризада белдерелгән Учреждение ихтыяҗын исәпкә алып, Гамәлгә куючы тарафыннан әлеге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum_{i=1}^{5} З_i,$$

биредә:

$З_1$ – Чараны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителә торган Учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү өчен Россия Федерациясенең хезмәт һәм салым законнары нигезендә Учреждениенең локаль норматив актларында каралган этәргеч бирүче һәм башка төр түләүләр, штат расписаниесе нигезендә вазыйфа окладларын исәпкә алып билгеләнә торган фондны формалаштыру чыгымнары;

$З_2$ – хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүләргә һәм учреждение хезмәткәрләренә Россия Федерациясенең хезмәт законнары һәм иминият кертемнәре турындагы законнары нигезендә билгеләнә торган башка түләүләргә мәҗбүри социаль иминиятләштерү кертемнәрен түләү чыгымнары;

$З_3$ – Россия Федерациясенең норматив актларын һәм Учреждение карарларын исәпкә алып, Учреждение ихтыяҗларына карап формалаштырыла торган хезмәткә түләү фондыннан тыш, учреждениеләрнең персоналына башка төрле түләүләр чыгымнары;

$З_4$ – элемтә хезмәтләре, мөлкәттән файдалану, мөлкәтне карап тоту һәм Учреждение ихтыяҗлары нигезендә башка эшләрне башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бер үк (бер төрле) товарларга, эшләргә, хезмәтләргә базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән оештыручы-әзерләүчеләрнең бәяләре турындагы, шулай ук, җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын да кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларындагы һәм махсус әдәбияттагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган, чагыштырма башар бәяләре (базарны анализлау) ысулы белән формалаштырылган чыгымнар;

$З_5$ – Учреждениенең финанс булмаган активлары артуга китерә торган, төп чараларның, матди булмаган активларның, җитештерелмәгән активларның, матди запасларның бәяләре артуына киткән чыгымнарны үз эченә ала торган, Татарстан Республикасы норматив актлары һәм Учреждениенең локаль норматив актлары белән җайга салына торган чыгымнары.

8. Гариза бирү көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычлары, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләре, бюджет инвестицияләре юк, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш.

9. Субсидияне бирү нәтиҗәсе булып, Учреждениенең әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән Чара нәтиҗәләре күрсәткечләренә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларына) ирешүе тора.

10. Гамәлгә куючы субсидияне Учреждениенең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап счетларына килешүдә каралган субсидияне күчерү графигы нигезендә тулы күләмдә күчерә.

## III бүлек. Хисаплылыкка карата таләпләр

11. Учреждение Гамәлгә куючыга хисаплылыкны түбәндәге чорларда тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган өч эш көне узганчы, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге үрнәк буенча финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап;

ай саен, хисап аеннан соң килә торган өч эш көне узганчы, раслый торган документларны тапшырып, әлеге Тәртинең 3 нче кушымтасы нигезендәге үрнәк буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап;

хисап елының соңгы аеның 25 көненнән соңга калмыйча, Чараны гамәлгә ашыру турында белешмәләр тапшырып, Гамәлгә куючы раслаган үрнәк буенча килешүне үтәү турында хисап;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган өч эш көне узганчы, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында әлеге Тәртинең 5 нче кушымтасы нигезендәге үрнәк буенча хисап.

Тапшырыла торган хисаплылык һәм кушымта итеп бирелә торган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш. Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, төзәтүләр рөхсәт ителми.

Гамәлгә куючы килешүдә өстәмә хисаплылык формаларын һәм чорларын билгеләргә хокуклы.

## IV бүлек. Субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольлекне һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру тәртибе

12. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы Учреждениегә субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен контрольдә тота.

Гамәлгә куючы субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән чыгып, субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыручы вакыйгаларга карап, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү мониторингын Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә үткәрә.

13. Учреждение субсидия алу өчен яки субсидиядән файдалану турында дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган, субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган, шулай ук әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән субсидияне тоту максатларын бозган, хисаплылык тапшырмаган өчен җаваплы була.

14. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә Учреждениенең субсидия бирү вакытында билгеләнгән максатны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, субсидия Гамәлгә куючының тиешле таләбе Учреждение тарафыннан алынганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән субсидияне бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, субсидия Гамәлгә куючының тиешле таләбе алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек чорда Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару чорын бозган очракта, Гамәлгә куючы әлеге чор узганнан соң, эш көннәрендә санала торган җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

16. Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Гамәлгә куючы Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып агымдагы финанс елының 1 гыйнварына тотылмаган субсидиянең калган өлеше булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләр булуы турындагы, субсидия бирү елыннан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате), шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатка ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатка ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карарны Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате алынган вакыттан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

17. Гамәлгә куючының агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең

калган өлешен әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатка ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карары нигезендә субсидиянең калган өлеше әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә максатка юнәлдерелгән чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен агымдагы елда файдаланылырга мөмкин.

18. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән максатка ирешү өчен элегрәк түләнгән түләүләрне кире кайтарудан акча күчкән очракта, Гамәлгә куючы Учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кайтарудан алынган акчалар торган үтәмәгән йөкләмәләр (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында субсидия бирелгән елдан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – Учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгате), шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен Учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Гамәлгә куючы әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатка ирешү өчен финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан күчкән акчаларны агымдагы финанс елында файдалану турындагы карарны Учреждение элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә
1 нче кушымта

Субсидияне бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре
(күрсәткечләрнең индикаторлары)

| № | Нәтиҗә исеме<br>(ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы)<br>Үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә күрсәткечләре (күрсәткечләрнең индикаторлары) |
|---|---|---|
| | | 2025 ел |
| 1 | Эшләнгән яңа уку-методик комплектларның (өстәмәләр белән) берәмлекләрнең саны, берәмлек | 2 |
| 2 | 6 басма кәгазь, 25 берәмлек тираж һәм 200 слайд күләмендә эшләнгән фәнни-методик продуктлар саны (презентацияләр, укыту-методик әсбаплар, предмет буенча дидактик материаллар җыентыгы, «Туган (татар) тел», «Туган (татар) телдәге әдәби уку», «Туган (татар) телдәге әдәбият», «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» (1 - 11 сыйныфлар өчен), хезмәт күрсәтү | 1 |
| 3 | Татар телен туган тел, туган тел булмаган һәм чит тел буларак укыткан Татарстан Республикасында яшәүчеләр саны, кеше | 225 |
| 4 | Татар теле һәм әдәбияты укытучылары, Россия | 50 |

| № | Нәтиҗә исеме<br>(ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы)<br>Үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә күрсәткечләре<br>(күрсәткечләрнең индикаторлары) |
|---|---|---|
| | Федерациясе субъектлары гомуми белем бирү оешмалары директорлары, квалификация күтәрү курсларында катнашучылар саны, кеше | |
| 5 | «Бала» балалар электрон китапханәсендә урнаштырылган мультимедиа интерактив балалар әсәрләре саны, берәмлек | 10 |
| 6 | «Татар иле» электрон мәктәп энциклопедиясе белән интеграцияләнгән «Мирас» электрон белем бирү басмасында урнаштырылган әсәрләр саны, берәмлек | 150 |
| 7 | «Татар иле» электрон мәктәп энциклопедиясе белән интеграцияләнгән «Мирас» электрон белем бирү басмасында татар телен өйрәнү буенча эшләнгән һәм урнаштырылган музыкаль өйрәтү сериаллары саны, берәмлек | 5 |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

20___ елның «___»__________ финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап

Гамәлгә куючының исеме ____________________________________________________

Учреждениенең исеме _______________________________________________________

Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесенә кадәр төгәллек белән)

| Субсидия | | Агымдагы финанс елы башына субсидиянең калган өлеше | | Килгән акчалар | | | Түләүләр | | Курс аермасы | Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атамасы | БК буенча коды | Барлыгы | Алардан файдаланырга рөхсәт ителгәне | Барлыгы, шул исәптән | Татарстан Республикасы бюджетыннан | Узган елларның дебиторлык бурычларын кире кайтару | Барлыгы | Шулардан: Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылган | | Барлыгы | Шул исәптән: | |
| | | | | | | | | | | | Шул ук максатлар өчен кирәк | Кире кайтарылырга тиеш |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) ___________________ __________ ______________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)
«___»_________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап

20____ елның 1________________ Дата

| КОДЛАР |
| --- |
| |
| |

Учреждение атамасы ______________________ _ Җыелма реестр буенча

Гамәлгә куючы атамасы _______________________ Җыелма реестр буенча

БК буенча атамасы _______________________

Документ төре _______________________

(беренчел – «0», тәгаенләштерелгән – «1», «2», «3», «...»)

Ешлыгы: ай саен, квартал саен, еллык

Үлчәү берәмлеге: сум ОКЕИ буенча

1. Субсидия бирү нәтиҗәләренең кыйммәтләренә ирешү һәм аларга ирешү максатында кабул ителгән йөкләмәләр турында мәгълүмат

| Чыгымнар юнәлеше | | Субсидия бирү нәтиҗәсе | Үлчәү берәмлеге | | Сызык коды | Планлы мәгънәләр | | Килешүдә каралган субсидия күләме | Чынлыкта ирешелгән кыйммәтләр | | | | | | Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү максатыннан кабул ителгән йөкләмәләр күләме | | Кулланылмаган финанс тәэминаты күләме (9 гр. - 16 гр.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | хисап датасына | | план күрсәткеченнән тайпылу | | тайпылу сәбәбе | | | | |
| Атамасы | БК буенча коды | | Атамасы | ОКЕИ буенча коды | | Килешү төзелгән көннән | Шулардан агымдагы финанс елы ба- | | Килешү төзелгән көннән | Шулардан агымдагы финанс елы ба- | Абсолют зурлыкларда (7 гр. - 10 гр.) | Процентларда (12 гр./7 гр.х 100%) | Коды | Атамасы | Йөкләмәләр | Акча йөкләмәләре | |

| | | | | | | | шын-нан | | | шын нан | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | Барлыгы: | | | | | | | Барлыгы: | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _______________________________ ___________ _________________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы ___________________ _________________________ _______________________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (телефон)

«__» __________20_ ел.

2. Субсидия бирү нәтиҗәләренең кыйммәтләренә ирешү турында хисап кабул итү турында мәгълүмат

| Күрсәткеч | Федераль | КОСГУ | Сумма |
|---|---|---|---|

| | бюджетның бюджет классифи-кациясе буенча код | | Килешү төзелгәннән бирле | шулардан агымдагы финанс елы башыннан |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән субсидия күләме | | | | |
| | | | | |
| Кирәклеге расланмаган субсидия күләме | | | | |
| | | | | |
| Бюджетка кайтарылырга тиешле субсидия күләме | | | | |
| Бюджетка күчерелергә тиешле штраф санкцияләре (пени) суммасы | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _________________________ ___________ _________________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы __________________ _________________________ ______________________________
(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (телефон)

«__» __________ 20_ ел.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 4 нче кушымта

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы

| Субсидияне бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | План күрсәткече | План буенча ирешү вакыты (көне, ае, елы) | Статусы | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атамасы | коды | тибы | атамасы | ОКЕИ буенча | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Алучының җитәкчесе (вәкаләтле зат) ______________ ______________ ______________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы ______________ ______________ ______________

(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (телефон)

«__» _________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы чараларын 2025 елда башкару белән бәйле чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен һәм аны бирү шартларын билгеләү тәртибенә 5 нче кушымта

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәләренә (контроль нокталарга) ирешү буенча чаралар планын гамәлгә ашыру турында хисап
20____ елның «__» _______ буенча

| КОДЛАР |
|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | Дата |
| | | Җыелма реестр буенча |
| Алучының исеме | | Салым түләүченең тәңгәллек номеры |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән төп эш итүченең исеме | (Министрлык) | Җыелма реестр буенча |
| Чараның атамасы | | БК буенча |
| Субсидия атамасы | | БК буенча |
| | | Килешү номеры |
| | | Килешү датасы |
| Документ төре | (башлангыч – «0», төгәенләштерелгән – «1», «2», «3», «...») | |

| Субсидияне бирү нәтиҗәсе, контроль нокталар | | | Үлчәү берәмлеге | | Билгесе | | | Ирешү вакыты (көне, ае, елы) | | Статусы | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атамасы | коды | тибы | атамасы | ОКЕИ буенча коды | план | хакыйкый | фараз | планлы | хакыйкый (фаразланган) | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Субсидия бирү нәтиҗәсе: | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |

Алучының җитәкчесе (вәкаләтле зат) _______________ _______________ _______________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы _______________ _______________ _______________

(вазыйфа) (фамилия, инициаллар) (телефон)

«__» _________ 20__ ел